Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы Иске Михайловка авыл җирлегенең
Каськи авылы гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы карары

9 декабрь 2023 ел №7

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына ярашлы рәвештә, 2023 елның 09 декабрендә 12 сәгать 00 минутта узган гражданнарның җыен нәтиҗәләре нигезендә түбәндәге: «Сез 2024 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Иске Михайловка авыл җирлеге Каськи авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 7500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы: торак пункт территориясен төзекләндерү (эскәмияләр, өстәлләр, биотуалетлар, вак таш сатып алу)?».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 20 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 12 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленгән:

«РИЗА» позициясе өчен гражданнар җыенының 10 катнашучысы тавыш бирә; «КАРШЫ» позициясе өчен җыенның 2 катнашучысы тавыш бирә.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Иске Михайловка авыл җирлегенең Каськи авылы гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыенының нәтиҗәләре - чынбарлыкка туры килә.

2. «Сез 2024 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Иске Михайловка авыл җирлеге Каськи авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 7500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы: торак пункт территориясен төзекләндерү (эскәмияләр, өстәлләр, биотуалетлар, вак таш сатып алу)?» турындагы мәсьәлә буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3.Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Иске Михайловка авылы, Мәктәп урамы, 43 йорт, Ирекле авылы, Урман урамы, 1а йорты, Каськи авылы, Полевая урамы, 15а йорт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендында халыкка җиткерергә, «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Иске Михайловка авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Иске Михайловка авыл җирлеге башлыгы А.Ю.Зарубин